**Хәмит БУЛАТОВ,**
*сугыш һәм хезмәт ветераны, композитор, бик күп җырлар авторы*

«Коммунизм байрагы» редакциясе каршында оештырылган әдәбият-сәнгать берләшмәсе башта «Чулпан» дип аталган иде. Аны оештыручы газетаның редакторы Хәнәфи Галиевич Маннапов иде.

Берләшмәнең даими секретаре Заһидә Нәбиуллина булып, ул һәр утырышның беркетмәсен язып бара иде. Берләшмәнең идарә членнары Хәниф Хөснуллин, Мәхмүт Газизов, Рәшит Юнысов, Зәйнәп Җиһаншина, Равил Вәлиев, Равил Лотфуллин булдылар. Соңрак берләшмәгә «Ләйсән» исеме бирелде.

Шул чорда берләшмәдә актив катнашкан иптәшләр Сәлимә Шәрипова, Мөслах Таҗиев, Разил Вәлиев, Мөдәррис Әгъләмов, Фәннур Сафин, Рафис Хисамиев, Шәүкәт Сибгатуллин, Николай Евстафьев, Анатолий Цыганов, Розалин Нәгыймуллин, Әлфия Шәрәфетдинова, Рәүф Гыйззәтуллин булды.

Шул дәвердә танылган язучылар һәм шагыйрьләр С. Хәким, Г. Ахунов, М. Хөсәен, З. Нури, Ә. Баян, Ш. Маннапов, Р. Мингалим, Р. Мостафин, Р. Гәрәй шәһәребездә берничә тапкыр булып җирле шагыйрьләр белән очрашып, аларга файдалы киңәшләр биреп килделәр. Берләшмә эшенә филология фәннәре кандидаты, язучы Эдуард Касыймов күп еллар буенча шефлык итте һәм җирле шагыйрьләрне һәм язучыларны үстерүдә күп ярдәм күрсәтте.

Мин, гади бер укучы һәм поэзиягә гашыйк бер кеше буларак, берләшмәнең һәр утырышында катнашып, поэзиягә булган мәхәббәтемне җирле шагыйрьләрнең әсәрләренә музыка иҗат итүем белән аңлатырга тырыштым. Мәсәлән, М. Әгъләмовның «Сөн буенда», Ф. Сафинның «Чит җирдә», С. Шәрипованың «Ак самолет», Николай Евставевның «Сине генә эзли күзләрем», Мөслах Таҗиевның «Яшел чыршылардан көнләштем», «Исеме – Түбән Кама», Р. Хисамиевның «Үзешчән артистлар җыры», «Яшәр идем туган авылда», Хәниф Хөснуллинның «Безнең бригада», «Ак болытлар», Риза Шәфиевның «Бала йоклатканда», Рәйсә Фәхразиеваның «Сөзәк ярда», «Зәңгәр кыңгыраулар», «Кышкы пейзаж», Салават Гатауллинның «Онытылмас сөю язларым», «Кыңгыраулар үскән үзәндә», Мәхмүт Газизовның «Бәхетле йолдыз тап», Әлфия Шәрәфетдинованың «Ничә еллар үткәч», Рахмай Хисмәтуллинның «Язгы кичтә» дигән әсәрләренә көйләр яздым.

*// Якты юл. – 1983. – 1 окт.*